ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апреля 2025 ел. № 122

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 елның 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2019-2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы 159 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 декабрендәге 3081-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү стратегиясен нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты. Программаны финанслау чыганакларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программа паспорты

| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме: | | |
|---|---|---|---|
| | ел | җирле бюджет | республика бюджеты |
| | 2023 | 199,8 мең сум | 128,12 мең сум (спорт җиһазлары);<br>399,0 мең сум (хоккей буенча программаларны |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | гамәлгә ашыруга) |
| | 2024 | 199,8 мең сум | 115,78 мең сум (спорт җиһазлары);<br>377,8 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга) |
| | 2025 | 199,8 мең сум | 134,09 мең сум (спорт җиһазлары);<br>470,7 мең сум. (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга) |
| | Барлыгы | 599,4 мең сум | 1 625, 49 мең сум |

1.2. 6 бүлек. Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары 2023-2025 елларга 5.6, 6.3, 6.6, 6.7 пунктлар түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чараларның эчтәлеге | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплы | Финанслау күләме (мең сум). | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2023 | 2024 | 2025 |
| 5.6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә спорт мәктәпләрен җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга бюджетара трансфертлар. (республика бюджеты) | 2023-2025 еллар | «Спорт мәктәбе» МБУ | 128,12 | 115,78 | 261,2 |
| 6.3 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә спорт әзерләү буенча программаларын гамәлгә ашыруга һәм спорт мәктәпләренең спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында (республика бюджеты) канашуына бюджетара трансферлар | 2023-2025 еллар | «Спорт мәктәбе» МБУ | 399,0 | 377,8 | 470,7 |
| 6.6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендщ | 2023-2025 еллар | «Спорт мәктәбе» МБУ | 2,8 | 40,0 | 40,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәлән расланган бюджетара трансфертлар | | | | | |
| 6.7 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен спортчылар - инструкторларга һәм спортчыларга бүләкләү өчен расланган бюджетара трансфертлар | 2023-2025 еллар | «Спорт мәктәбе» МБУ | 100,0 | 100,0 | 130,0 |

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Физик культура һәм спорт» тармаклары буенча каралган бюджет чаралары кысаларында муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет акчалары бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Н. Бадахшинга йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**